| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО<br>ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И<br>СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ<br>РЕСПУБЛИКИ<br>ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ<br>БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ<br>СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ<br>МИНИСТРЛЫГЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

09.04.2020 г.Казань № 238

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2020 елның 29 апрелендә 6642 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының 2018 елның 6 апрелендәге «Авыл җирендә, шәһәр тибындагы бистәләрдә даими яшәүче хатын-кызларга, бала туганда, бер тапкыр бирелә торган түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 254 санлы боерыгы белән расланган авыл җирендә, шәһәр тибындагы бистәләрдә яшәүче хатын-кызларга, бала туганда, бер тапкыр бирелә торган түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Авыл җирендә, шәһәр тибындагы бистәләрдә даими яшәүче хатын-кызларга, бала туганда, бер тапкыр бирелә торган түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р а м:

Татарстан Республикасы «Татарстан Республикасының Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының 2018 елның 6 апредлендәге «Авыл җирендә, шәһәр тибындагы бистәләрдә даими яшәүче хатын-кызларга, бала туганда, бер тапкыр бирелә торган түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы 254 санлы карары белән расланган авыл җирендә, шәһәр тибындагы бистәләрдә даими яшәүче

хатын-кызларга, бала туганда, бер тапкыр бирелә торган түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында (Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының 2018 елның 25 июлендәге 703 санлы, 2018 елның 18 сентябрендәге 885 санлы, 2019 елның 24 июнендәге 494 санлы, 2019 елның 17 октябрендәге 853 санлы боерыкларына кертелгән үзгәрешләр белән) кушымта итеп бирелә торган үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Министр Э.А. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2020 елның 9 апрелендәге 238 санлы боерыгы беләнрасланган

Татарстан Республикасы
Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының 2018 елның 6 апрелендәге «Авыл җирендә, шәһәр тибындагы бистәләрдә даими яшәүче хатын-кызларга, бала туганда, бер тапкыр бирелә торган түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы 254 санлы боерыгы белән расланган авыл җирендә, шәһәр тибындагы бистәләрдә даими яшәүче хатын-кызларга, бала туганда, бер тапкыр бирелә торган түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы административ регламентына үзгәрешләр кертелә

1.2 пунктның өченче абзацында «өченче» сүзеннән соң «һәр алдагы» сүзләрен өстәргә;

2.4 пунктның 2 бүлегендәге «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасының өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бер тапкыр бирелә торган түләүне билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү бер тапкыр бирелә торган түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул ителгән көннән бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла»;

1 нче кушымта текстында «(беренче) өченче)» сүзләрен «(беренче )өченче һәм һәр алдагы)» сүзләренә алмаштырырга.